| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**04.12.2015** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2683** |

Дәүләт милке чикләнмәгән һәм җирле үзидарә органнары белән эш итү хокукына ия булган җир кишәрлегендә, Зеленодольск муниципаль районы милкендә һәм Зеленодольск муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын сүтү кирәк булган очракларда, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына муниципаль заказчы тарафыннан хәбәр бирү тәртибен раслау турында

2014 елның 13 мартындагы «Реклама турында» 38-ФЗ номерлы Федераль закон, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 5 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районында реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» 503 номерлы карары, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәнең гамәлдә булуын туктатып тору (туктату) процедурасын җайга салу максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Дәүләт милке чикләнмәгән һәм җирле үзидарә органнары белән эш итү хокукына ия булган җир кишәрлегендә, Зеленодольск муниципаль районы милкендә һәм Зеленодольск муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын сүтү кирәк булган очракларда, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына муниципаль заказчы тарафыннан хәбәр бирү тәртибен, 1нче кушымтада каралганча расларга;
2. ЗМР Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына ТР хокукый мәгълүмат сайтында pravo.tatarstan.ru һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru/ урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С.Г. Егоров

Зеленодольск
муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына
04.12.2015 ел N 2683
1 нче кушымта

**Дәүләт милке чикләнмәгән һәм җирле үзидарә органнары белән эш итү хокукына ия булган җир кишәрлегендә, Зеленодольск муниципаль районы милкендә һәм Зеленодольск муниципаль районы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын сүтү кирәк булган очракларда, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына муниципаль заказчы тарафыннан хәбәр бирү тәртибе**

1. Реклама конструкциясе һәм тышкы мәгълүмат чарасы кушылган мөлкәт төзелеше, сүтелү, реконструкция, ремонт , шулай ук инженерлык коммуникацияләрен салу, ремонтлау, реконструкцияләү белән бәйле реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын сүтү кирәк булган очракта, күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашыручы муниципаль заказчы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә, реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын сүтәргә кирәклеге турында, планлаштырыла торган эшләр тәмамлану датасын күрсәтеп, таләп ителгән сүтү датасына кадәр 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, йә элеккеге урында реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын торгызуның мөмкин булмавын күрсәтеп, язмача мөрәҗәгать җибәрә;

2. Күрсәтелгән эшләр төрләрен үткәрү срогын озайткан (кыскартылган) очракта, муниципаль заказчы, төзелеш эшләрен тәмамлауның яңа датасын күрсәтеп, бу хакта Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш;

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге эш төрләрен үткәрүгә комачаулаучы реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау турындагы таләбе, аның хуҗасына мондый сүтү кирәклеге турында муниципаль заказчыдан язмача мөрәҗәгать алган мизгелдән , бер эш көне эчендә җибәрелә;

4. Реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын вакытлыча сүтү, әлеге эшләрне башкару зарурлыгына бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә буенча исәпләүләрне, элеккеге урында торгызу мөмкинлеге барлыкка килгәнче, туктатып тору өчен нигез булып тора;

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау заруриылыгы турындагы язмача мөрәҗәгать, аны элеккеге урында торгызу мөмкинлеге булмауны күрсәтелеп, Зеленодольск муниципаль районы

территориясендә реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә өзелү өчен нигез булып тора;

6. Күрсәтелгән эш төрләрен үткәрүгә комачаулаучы реклама конструкциясен һәм тышкы мәгълүмат чараларын демонтажлау, вәкаләтле органның демонтаж кирәклеге турында таләбе алынган вакыттан алып, 10 эш көне эчендә, аның хуҗасы тарафыннан үз хисабына башкарыла